**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 22 » 05 2018 ел** **№ 106**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 17 маендагы 168 номерлы карары белән расланган муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә Азнакай муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 485-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 17 маендагы 168 номерлы карары белән расланган муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә Азнакай муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентына түбәндәге эчтәлекле 2.4.4 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

2.4.4. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.4.3 пунктында күрсәтелгән нигезләр белән беррәттән, торак коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасында муниципаль торак контроле органы тарафыннан түбәндәгеләрне ачыклау нигез була:

1) күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләрен бозу турында;

2) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм торак урынны карап торкан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу турында;

3) җирле үзидарә органнары, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, гражданнар тарафыннан торак - коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр бозылу турында. "

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Интернет-телекоммуникация челтәренең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов